РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» март 2025г. г. Альметьевск №165

Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы карарының кушымтасына (Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2019 елның 16 декабрендәге 182 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 26 номерлы, 2021 елның 17 июнендәге 36 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 69 номерлы, 2023 елның 29 мартындагы 104 номерлы, 2023 елның 6 декабрендәге 130 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның «Шәһәр башкарма комитеты вәкаләтләре» 2 бүлегендә:

1.1.1 2.2 пунктының 7 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.»;

1.1.2. 2.3 пунктның өченче абзацында «федераль законнар белән» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарга 1 нче кушымтаның «шәһәр Башка рма комитеты җитәкчесе» 3 бүлегендә:

1.2.1. 3.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.6.1 пунктчасы өстәргә:

«3.6.1. Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса.»;

1.2.2. 3.12 пунктның егерменче абзацында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.Ә.).

Шәһәр башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Р. Баһманов

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» • РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» ГОРОДСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ «ГОРОД АЛЬМЕТЬЕВСК» • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» «ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ» ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ